**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

19.11.2024 № 1280-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 5 августындагы 667-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 5 августындагы 667-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 12.10.2023 ел, №1186-п, 08.02.2024 ел, №126-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм алардан файдалануга лицензияләр бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча

дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.6.1 пунктта:

«р» пунктчасында «( «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $10^1$ ст. 1 өлешендәге 1 пункты)» сүзләрен «, - төзелгән шартнамәләр, дәүләт контрактлары нигезендә эшләр уздырылган очракта» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «т» һәм «у» пунктчалары өстәргә:

«т) магистраль нефть үткәргечләрне, нефть продуктлары үткәргечләрен һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга, күрсәтелгән эшләрне башкаруга граждан-хокукый шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган шартнамә күчермәсе – эшләр төзелгән шартнамәләр, дәүләт контрактлары нигезендә башкарылган очракта;

у) магистраль газүткәргечләрне һәм аларның аерылгысыз технологик өлешләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга, күрсәтелгән эшләрне башкаруга граждан-хокукый шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган шартнамә күчермәсе – эшләр төзелгән шартнамәләр, дәүләт контрактлары нигезендә башкарылган очракта.».

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары А.А.Тугушевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков